УДК 94(47).08

*И.К. Заһидуллин*

# МӨСЕЛМАН РУХАНИЛАРЫНЫҢ 1905 ЕЛГЫ УФА КОРЫЛТАЕ

В статье вкратце рассматриваются причины и проведение известной в исторической литературе как «Собрание улемов», или «курултай», совещания мусульманского духовенства, состоявшего 10–15 апреля 1905 г. в г. Уфе в здании Оренбургкого магометанского духовного собрания. Также перечисляются основные проекты по реформированию управления духовными делами мусульман округа. Констатируется, что уфимское совещание улемов стало важным событием на начальным этапе становления национального движения мусульман в 1905 г. Статья написана в качесте предисловия к проектам, публикуемым из книги Муса Бигиева «Ислахат әсаслары».

**Ключевые слова:** Первая русская революция 1905–1907 гг., уфимский курултай мусульманских духовных лиц (10–15 апреля 1905 г.), проекты реформирования управления духовными делами в округе Оренбургкого магометанского духовного собрания, Муса Бигиев, оренбургский муфтий М. Султанов, Р. Фахретдин.

Атеистик Россиянең дөньяви җәмгыятькә йөз белән борылуы, совет һәм марксистик-ленинчыл идеологиягә нигезләнгән фәнни эзләнүләргә тәнкыйди караш көчәю тарих фәнендә моңарчы өйрәнелмәгән яки махсус рәвештә тыелып килгән темаларга һәм фәнни юнәлешләргә юл ачты. Бу яңа күренешләр Татарстан гуманитар фәнен дә читләтеп узмады.

Диннең халкыбызның гореф-гадәтләрен, көнкүрешен, әхлак нормаларын, мәдәниятен формалаштыруга зур йогынты ясавы мөселманнар арасында ислам институтларының төрле тарихи чорларда тоткан урынын ачыклау мәсьәләсен махсус өйрәнү бурычы куйды. Соңгы елларда бу юнәлештә башкарыла торган фәнни эзләнүләрнең һәм теоретик, һәм сәяси, һәм гамәли әһәмияте артты. Мондый ихтыяҗның ике зур сәбәбен атап үтү зарур. Беренчесе – соңгы дистә елда дөньяда һәм илебездә мөселманнарга террористлар, экстремистлар һәм кешелек җәмгыятенә, гомумән гуманизмга каршы кара көч итеп карауның җәелүе һәм кайбер очракларда мондый карашларның хәтта өстенлек ала башлавы. Әлбәттә, исламофобия күренешләренә һәм нахакка гаепләүгә каршы төрле юллар белән каршы тору, көрәшү сорала. Икенчесе – диннең дәүләттән аерылган булуы шартларында җәмгыятебездә шәригать нормаларының яшәеше, төрле-төрле исемдәге мөфтиятләрнең, ислам институтларының үсеше, аларның эшчәнлеген заман ихтыяҗларына яраклаштыру мәсьәләсе.

Россия составында яшәгән дәвердә дәүләт – ислам мөнәсә-

бәтләренең эчтәлеге сугышчанлыктан килешүчәнлек ягына үзгәреш кичерә. Екатерина II заманында ислам диненә карата урнашкан түземле мөнәсәбәт Кавказ сугышы һәм 1863 елгы Польша восстаниесе йогынтысында кабат начар якка үзгәрә башлый. XIX гасырның икенче яртысында империя хакимиятенең мөселман булган кешегә шикчел мөнәсәбәте гадәти күренешкә әверелә. XX гасыр башында татарларны рәсми рәвештә панисламизмда, пантюркизмда, пантатаризмда гаепләгәннәр. Шул ук вакытта татарлар үзләренең дини һәм гражданлык хокуклары өчен мөмкин булганча көрәшкәннәр дә, яңа иҗтимагый шартларга яраклашырга да мәҗбүр булганнар. Гомумиләштереп әйткәндә, татар җәмгыятендәге моннан 100 элек булган халәт белән бүгенге иҗтимагый тормыш арасында күп кенә уртаклыклар табып була.

Югарыда аталган сәбәпләр йогынтысында Татарстанда соңгы ун-унбиш елда гуманитар өлкәдә мөселманнарның фикер сөрешенә һәм социаль тәртипләренә бәйле тема-сюжетларны өйрәнүгә игътибар арту күзәтелә.

Бүгенге тормышыбызга турыдан-туры кагылган шундый вакыйгаларның берсе – тарихи әдәбиятта «Голәмә җәмгыяте», яки «Корылтай», исеме белән мәгълүм булган 1905 елның 10–15 апрель көннәрендә Уфа шәһәрендә Мәхкәмәи шәргыя Ырынбургия бинасында узган руханилар корылтае. Бу вакыйга хакында фәнни даирәләрдә мәгълүмат аз булуның берничә сәбәбе бар. Беренче сәбәп – Корылтайда кабул ителгән документның матбугат битләрендә күренмәве, ягъни киң җәмәгатьчелеккә барып җитмәве, һәм Эчке эшләр министрлыгының архивында югалуы. Чыннан да, беренче карашка, төрле купшы сүзләр сөйләп һәм азактан берни эшләнмәгән, кем әйтмешли, бәлеш ашау мәҗлесләре тарихыбызда аз түгел бит! Икенчесе – Мәхкәмәи шәргыя Ырынбургия казыйлары һәм зыялылар тырышлыгы белән корылтай әзерләгән документ-проект мөселманнарның дини идарәләрен үзгәртеп коруга һич кенә дә йогынты ясамый. Корылтай карарларының исәпкә алынмавына һәм тормышка ашырылмавына империя хакимияте гаепле иде.

Безнең игътибарны Корылтайда яңгыраган яңа фикерләр җәлеп итте. Анда тикшерелгән мәсьәләләрдә, бирелгән тәкъдимнәрдә, проектларда Идел – Урал төбәгендә көн итүче төрле социаль катламга караган һөнәр ияләренең һәм җәмәгать эшлеклеләренең, гомумән, милләт язмышына битараф булмаган шәхесләрнең киләчәкне фаразлау планнары чагылыш тапкан. Аларда сүз дини идарәгә реформа ясау, ислам институтларының хокукларың киңәйтү, башка конфессияләр белән тигез хокукларга ирешү кирәклеге, шуның юллары турында бара. 1905–1907 еллардагы Беренче рус революциясе алып килгән демократия һәм сүз иреге шартларында якты киләчәк турындагы хыял һәм илдә тигез хокуклы гражданнар булу планнары белән сугарылган мөселман кардәшләребезнең моннан 112 ел элек

яңгыраган сүзләре тирән мәгънәгә ия булуы, ә кайвакыт самимилеге белән дә игътибарга лаек.

«Иттифак әл-мөслимин» партиясенең өч съездының дә сәркатибе сыйфатында утырышларның протоколларын алып барган, күренекле җәмәгать эшлеклеләре белән аралашкан Муса Бигиев, Россиядә һәм мөселманнар арасында җәелгән иҗтимагый хәрәкәтнең милли тарих өчен олы әһәмиятен аңлап, XX гасыр башы ислахат хәрәкәтенең барышын, аның күренекле сәхифәләрен киләчәк буыннарга җиткерү бурычын куя. Муса Бигиевнең 1904–1915 еллардагы Идел – Урал төбәгендә яңарыш хәрәкәтенә багышлаган «Ислахат әсаслары» исемле хезмәте 1917 елда Петроградта М.-А. Максутов типографиясендә басыла.

Китапның эчтәлеген күз алдына китерү өчен, аның бүлекләрен, аларда кузгатылган темаларны искә төшерү мәслихәт булыр. Алар түбәндәгеләр: Габдерәшит Ибраһимовның, 1904 елның көзендә һәм кышында Идел – Урал төбәге мөселман лидерлары белән аралашып, хөкүмәт исеменә гаризалар бирү кампаниясен һәм фирка оештыру буенча иҗтимагый эшчәнлеге; 1905 елның 10–15 апрелендә Мәхкамәи шәргыя Ырынбургия бинасында узган мөселман руханилары корылтае, анда каралган проектлар һәм кабул ителгән проект, аңа бәйле текстлар; 22, 23 һәм 25 июнь көннәрендә узган Уфа губернасы мөселман вәкилләре җыелышы карарлары; Министрлар комитетына петицияләр бирү кампаниясе һәм Идел – Урал һәм Кавказ мөселманнарының гаризаларында билгеләнгән төп мәсьәләләр; «Иттифак әл-мөслимин» партиясенең өч съезды һәм аларның карарлары; 1905–1907 елгы инкыйлаб көннәре һәм 1905 ел 17 октябрь манифесты; Русиянең көнчыгышында һәм көньяк-көнчыгышында яшәгән инородецлар башлангыч мәктәпләре өчен Халык мәгарифе министрлыгы кабул иткән 1906 ел 31 март Кагыйдәләре; китап төзүченең дини мәктәпләр, мәдрәсәләр хакында фикерләре; Дәүләт думасы карарлары һ.б. урын алган. Әйтергә кирәк, бу материалларның кануннарга, хакимият карарларына һәм эшчәнлегенә кагылышлылары – гомумбилгеле фактлар. Бүгенге көндә бу хезмәтнең «Иттифак әл-мөслимин» партиясе съездына кагылышлы өлешләре киң әйләнешкә кертелгән. XX гасыр татар иҗтимагый хәрәкәтенең төп юнәлешләрен һәм этапларын «дөрес бәяләмәләр» куеп билгеләгән Галимҗан Ибраһимов үзенең «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре» [Ибраһимов, б. 212–435] исемле китабында Муса Бигиев текстын астөшермәләр куеп та, куймыйча да киң файдалана. Большевик-язучы шушы китаптан алган фактларга сыйнфый көрәш күзлегеннән бәя бирә. Муса Бигиевнең китабын шул рәвешле Беренче рус революциясе, «Иттифак әл-мөслимин» партиясе турында хезмәтләр язган башка татар тарихчылары да файдаланалар [Хасанов, 1985].

1905 елда Уфада узган мөселман руханилары корылтаен

яңача, уңай күренеш һәм җәелеп килүче яңарыш хәрәкәтенең мөһим бер вакыйгасы буларак, беренче булып, Төркиядә яшәп иҗат итүче тарихчы Надир Дәүләт бәяләде, үзенең «Русия төркиләренең милли көрәш тарихы (1905–1917)» исемле китабында шулай ук Корылтайда тикшерелгән проектларны да кыскача тасвирлады [Дәүләт, б. 75–79].

Россия галимнәре бу корылтай турында баштарак сүз уңаеннан, Беренче Рус революциясе елларында Идел–Урал төбәгендә формалашкан мөселман либераль хәрәкәтен өйрәнү кысаларында яки 1905 елгы милли хәрәкәтнең бер күренеше буларак, шул исәптән петицияләр бирү кампаниясенә бәйле рәвештә яздылар [Сенюткина, с. 31–32; Исхаков, с. 124; Фархшатов, с. 81 һ.б.]. А.Ю. Хабетдинов беренчеләрдән булып Корылтайда яңгыраган Ризаэддин Фәхретдин һәм Йосыф Акчура (тагын берничә татар бае) проектлары турында хезмәтләр бастырды [Хабутдинов, 2010, с. 166–167; Хабутдинов, 2011, с. 30–35; Хабутдинов, 2013, с. 73–75], И.К. Заһидуллин Йосыф Акчураның шушы өлкәдәге проектлары турында [Загидуллин, 2016, с. 123–127], Л.Ф. Байбулатова Ризаэддин Фәхретдиннең 1905 елгы проектын бәян итте [Байбулатова, с. 35–40] .

Ягъни корылтайда тикшерелгән Ризаэддин Фәхретдин һәм Йосыф Акчура, аларның фикердәшләре төзегән проектлар бүген инде фәнни әйләнешкә керде, дип әйтергә мөмкин. Ә менә башка, төрле яшьтәге, төрле фикердәге мөселманнар төзегән проектлар һаман да күз уңыннан читтә калып килә.

М. Бигиев, үзе корылтайда булмау сәбәпле, аның утырышлары турында катнашкан кешеләрдән ишеткәннәрен яза. Ул Корылтайда тикшерелгән проектларның текстларын кулга төшереп[1], аларны китабында сүзгә-сүз китергән дияргә мөмкин. Бу нәүбәттән «Ислахат әсасларын» хаклы рәвештә документлар чыганагы дип тә бәяләргә мөмкин. Дөрес, автор аларның кайберләрен бераз үзгәртеп, мәсәлән, Р. Фәхретдинекен [шунда ук, б. 75], яки кыскартып (Г. Дибердиевның 25 маддәдән торган проектыннан үзе мөһим санаган 14 маддәсен, Ш. Минушевның 33 маддәдән торган проектыннан башкаларда кабатланмаган 7 маддәсен генә урнаштыра) яза; шулай ук мөфти төзегән 70 маддәдән торган проект тәрҗемәсенең үзенең китапханәсендә сакланганын искәртә [шунда ук, б. 107], М. Солтановның премьер-министр С.Ю. Виттега 1905 ел 12 май көнне юлланган хатын татарчага шактый гадиләштереп тәрҗемә итә [шунда ук, б. 139–142].

Рус-япон сугышында Россия хурлыклы рәвештә җиңелүгә дучар булгач, җәмгыятьтә хакимияттән ризасызлык хисе көчле ташкын булып тышка бәреп чыга, төрле катлам вәкилләренең протесты хакыйкать, ирек һәм кимсетү-рәнҗетүгә каршы чыгышларга әверелә. Үзәк хакимияткә Санкт-Петербургта 1905 елның 6–8 ноябрь көннәрендә күпчелеге дворяннардан – самодержавиенең таянычы булган катлам вәкилләреннән –

торган губерна земство оешмалары җитәкчеләренең һәм башка земство әһелләренең съезды искитмәле йогынты ясый. Әле йокы халәтендә булган татарларны уятуда Габдерәшит Ибраһимовның иҗтимагый эшчәнлеге дә игътибарга лаек. Төркиядән кайтып, руслар арасындагы иҗтимагый хәрәкәтне күреп, земство вәкилләренең съезды резолюциясендә язылган ил халыкларына демократик ирекләр бирү, һәркемнең канун алдында тигезлеген тәэмин итү һәм башка хокуклар турында таләпләрен укып әсәрләнгән Габд. Ибраһимовның якын киләчәккә планнарын формалаштыруда эчке эшләр министры либерал фикерле Святополк-Мирский белән очрашу хәлиткеч роль уйный. Илдәге «тәртипсезлекләр» турында хәбәрдар булган һәм хөкүмәтнең «җәмгыятькә ышаныч сәясәтен» тормышка ашыручы министр мөселманнарга да үз таләпләре белән үзәк хакимияткә мөрәҗәгать итәргә киңәш бирә. Озак та үтми, 1904 елның 12 декабрендә, императорның махсус Указы дөнья күрә, анда илдә, шул исәптән дәүләт-чиркәү мөнәсәбәтләре өлкәсендә дә, киң масштабта реформалар уздырылачагы хакында хәбәр ителә. Һәркемнең канун алдында тигезлеген тәэмин итеп, кимсетүгә корылган кануннар юкка чыгарылачак, дип император Николай II үзе белдерә. Ышанмый кара.

Габд. Ибраһимовның төбәкләргә сәяхәт итеп, җирле мөселман җәмәгать эшлеклеләре белән аралашу-фикерләшүенең зур бер нәтиҗәсе булып 1905 ел 23 гыйнвар көнне аның инициативасы белән оештырылган һәм аның рәислегендә Казанда Әхмәт бай Хөсәенев йортында узган мәҗлесне атарга кирәк [Татария..., с. 47]. Анда хөкүмәт исеменә мөселманнарның ихтыяҗлары турында русча петиция бирү хакындагы карар кабул ителә, текстны язу Сәетгәрәй Алкинга йөкләнә. Габдулла Апанаев, Сәетгәрәй Алкин, Йосыф Акчура Казан мөселманнары вәкилләре итеп сайлана. Соңрак аларга сәүдәгәр Әхмәтҗан Сәйдәшев тә кушыла. Шушы вакыйгадан соң мөселманнар арасында Министрлар комитеты исеменә петицияләр бирү хәрәкәте җәелә, казанлылар депутациясе, мөселманнар арасында беренчеләрдән булып, 1 март көнне ул петицияне Министрлар комитеты рәисе С.Ю. Виттеның кулына тапшырып та кайта.

Шушы тарихи мәҗлеснең икенче көнендә Габд. Ибраһимов, Йосыф Акчура һ.б. кайбер фикердәшләр җыелып, Санкт-Петербургта гомум Русия мөселманнары исеменнән бер съезд ясау өчен, Кырым, Кавказ, казакъ, Төркестан мөселманнарына чакыру язу карарын кабул итәләр. Шулай итеп, Казанда Габд. Ибраһимов инициативасы белән ике зур чара бер вакытта диярлек башланып китә.

Министрлар комитетына төрле төбәкләрдән килгән петицияләрдә, үзәк мәсьәлә буларак, дини эшләр белән идарә итүне үзгәртеп кору, ислам институтларының хокукларын киңәйтү турында гозерләр еш кабатлана, шул сәбәпле 1905 елның 10 март көнне премьер-министр С.Ю. Витте

мөфти Мөхәммәдъяр Солтанов белән очрашканда руханилар катнашында мәҗлес ясап, шушы мәсьәләләрне тикшереп, «бер нәрсә» әзерләп хөкүмәткә җиткерү зарурлыгын күрсәтә [Исхаков, с. 124]. Биредә мөфтине һәм казыйларны мактап бер кәлимә сүз әйтәсе килә. Алар, тарихи мизгелнең әһәмиятен тирәнтен аңлаган хәлдә, С.Ю. Витте әйткән «бер нәрсә»не Мәхкамәи шәргыя һәм аның округына кергән ислам институтларының уставы рәвешендә эшләргә карар кылалар. Бу юнәлештә инде шактый фикер тупланган була.

Мөфти, озакка сузмыйча, гыйлемле, авторитетлы руханиларга телеграмма-чакырулар юллап, Уфага эндәшә. Чакыруның сәбәбе күрсәтелми: күпчелек яңа устав проекты әзерләү мәҗлесенә бернинди әзерлексез килә. Әмма әзерләнеп килүчеләр дә була.

Мөфти чакыруын игътибарга алып килгән 27–30 рухани һәм шәһәргә очраклы яки махсус рәвештә килгән берничә мулла, һәммәсе 39 имам[2] катнашында 10 апрельдә, якшәмбе көнне, иртә сәгать сигездә Мәхкамәи шәргыя Ырынбургия бинасының флигель залында корылтайны ачып, мөфти Мөхәммәдъяр Солтанов кыска гына нотык тота. «Җәмәгать! Дини-иҗтимагый әхвалемезне ислах итмәк, әлбәттә, җөмләмезнең матлубыдыр. Шул көнге хәлемезне төзәтү үземез өчен никадәр матлуб исә, дәүләт өчен дә, хөкүмәт өчен дә матлуб улса кирәк. Төзәтү юлларын, ислах рәвешләрен һәрбер халык үзе, әлбәттә, яхшырак белер. Ислах итү тиеш хәлләрен халык күрсәтсә, хөкүмәт, әлбәттә, мөмкин кадәр кабул итәр.

Минем фикеремчә, ислах эшләре иң элек дини мәсьәләләрдән башланмак тиештер. Әлбәттә беләсез, дини эшләремез 11 нче том беренче кыйсем 6 нчы китапта язылган низам маддәләренә муафыйк ижра кылынып килә. Буңа күрә, дини эшләремезне ислах итәек дисәк, әлбәттә, 6 нчы китап маддәләрен тәкъмил итеп тәгъдил итү [гадел хәл итү] тиеш улыр. Иштә хәзрәтләр! Оренбург, Кырым, Тифлис идарә руханияләренә гаид бөтен низамнар, төркичә тәрҗемәләре илә бәрабәр, яныгызда хәзердер. Моталәгa кылыңыз, тиеш тәгъдилат хакында фикерләреңезне языңыз. Бәгъзе маддәләре бәлки истифсар [тулы аңлатуны сорау] хаҗәт улыр, буңа күрә, казыйларның бере һәрвакыт бу рәддә булыначактыр. Мөзакәрәләрдә иштирак шәрәфе миңа насыйп улмас. Үзеңез, иншалла, яхшы гына мөзакәрә итәрсез. Хәерле сәгатьтә!» [Җарулла Муса, б. 16–17]. Күрәбез, мөселман җәмгыятенең ислах эшләре иң элек дини мәсьәләләрдән башланырга тиеш, ислах ителергә тиешле мәсьәләләрне халык күрсәтсә, хөкүмәт аны кабул итәчәк дигән фикерне ассызыклап, мөфти мәҗлесне ачык дип белдерә.

Мөфти планлаштырганча, башта Корылтайда Кавказ арты сөнни мәзһәбтәге руханилар идарәсе һәм Ырынбургия мәхкамәи шәргыя уставлары кычкырып укыла. Әлбәттә, бу уставлар нигезендә генә әзерлексез килеш ниндидер яңа фикер әйтеп булмый. Моннан тыш, муллаларның дини

уку йортында гына белем алган булуларын, Россия кануннарын белмәүләрен, чамаласалар да, төгәл итеп әйтеп бирү кыенлыгын да күздән ычкындырмаска кирәк.

Корылтайның беренче көнге икенче утырышында ил тарихында тәүге тапкыр мөселманнар арасында, «Русия мөселманнарының дини хаҗәтләре бер, яшәп килгән дүрт дини идарә[3] өстенә тагын бер идарә лаземме, аерым-аерым берничә дини идарәнең булуына ихтыяҗ бармы, Русия мөселманнарының дини башлыгы шәйхелислам булырга тиешме», дигән сораулар тирәсендә бәхәс башлана [Җарулла Муса, б. 39–42]. Төрле фикерләр яңгырый, кайберәүләр баш дини идарә булса, Мәхкамәи шәргыя Ырынбургиянең дәрәҗәсе төшәргә мөмкин дигән фикер дә белдерәләр. Икенче көнге иртәнге утырышта сөйләшү дәвам итә. Ахыр чиктә, Корылтайда катнашучылар үзәк дини идарә оештыру фикерен дә, шәйхелислам институтын булдыруны да хупламыйлар.

Мөфти М. Солтанов устав проектын Корылтай тарафыннан эшләнергә тиеш дип саный, үзеннән гел гаеп эзләп торган муллаларның «алдан әзерләнгән документны кабул итәргә мәҗбүр иттеләр» дигән ямьсез сүзләрен ишетергә теләми. Муллалардан устав проектының нигезе булырлык фикерләр ишетүдән өмете өзелгәч кенә, ул казый Ризаэддин Фәхретдингә корылтайга әзерлек йөзеннән эшләнгән проектын тикшерүгә чыгарырга рөхсәт бирә. Ризаэддин Фәхретдиннең проекты – казыйның берничә ел дәвамында уйлаган фикерләренең нәтиҗәсе, иң соңгы тапкыр күчереп язган варианты була. Шул сәбәпле, аның 111 маддәдән торган тексты [шунда ук, б. 52–75] Корылтай проектының нигезе буларак кабул ителә.

Уфадан рәсми чакырулар җибәрелмәсә дә, Корылтайга дип, ахун-муллалардан тыш, сәүдәгәрләр, зыялылар да җыела. Алар турыдан-туры корылтай эшендә катнашмасалар да, сөйләнгән сүзләрдән хәбәрдар булалар, руханилар белән дә еш аралашалар. Корылтайда катнашучылардан Йосыф Акчура, Абүсогуд Әхтәмев, Ибраһим Акчура, Сәетгәрәй Алкин, Мәхмүт Хөсәенев, Мөхәммәтзакир Рәмиев, Мөхәммәтйосыф Дибердиев имзалаган устав проекты белән танышалар [шунда ук, б. 42–49]. Корылтайның дүртенче утырышыннан Р. Фәхретдин проекты белән танышу һәм аның буенча фикер алышу башлана.

Корылтайга җибәрелгән тагын берничә проект муллаларның карашларын киңәйтеп җибәрә. Алар Уфа мәдрәсәләренең 90 шәкерте кул куйган 28 маддәле петиция [шунда ук, б. 79–82], корылтайда катнашучы руханилар төзегән 18 маддәдән торган тәгъдимнәр [шунда ук, б. 83–84], Габдулла Дибердиев биргән проект [шунда ук, б. 84–85], Тау авылыннан имам Сәһман Исхакый язган гариза [шунда ук, б. 86–91], Казан өязе Кече Солабаш авылы имамы Хәсәнгата Габәшинең проекты [шунда ук, б. 99–105], Абүсогуд Әхтәмевнең Мәхкамәи шәргыя турында 6 маддәдән торган фикере [шунда ук, б. 105–106], Самара шәһәре ахуны Шиһабетдин

Минушевның проекты [шунда ук, б. 106–108] белән танышалар. Корылтайда катнашкан 12 мулла белән мәҗлесләрдә рәисе булган Казанның Печән базары мәчете имамы Габдулла Апанаев кул куя [шунда ук, б. 91–99].

Без Ризаэддин Фәхретдин һәм Йосыф Акчура (тагын берничә татар бае) проектлары белән танышуны мәкаләбез азагында урнаштырылган әдәбият исемлегенә юллап һәм бу басмаларны Интернеттан да табып булу хакында искәртеп, укучыларыбыз игътибарын мөселманнарның фикерләрен шәрехләргә мөмкинлек бирә торган башка проектларга юнәлтергә булдык.

Аларда кайбер фикерләр кабатланса да, мондый кабатлану очраклары фәкать аларның төрле катлам вәкилләре арасында киң таралуын раслаучы факт булып тора.

Муса Бигиевның «Ислахат әсаслары» китабыннан югарыда аталган петиция һәм проектлар текстларын гарәп имласыннан кириллицага Казан федераль университетының Н.И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсе хезмәткәре Шәрәфиева Рәйсә Гамир кызы күчерде.

**Искәрмәләр**

[1] Ризаэддин Фәхретдин шәхси китапханәсеннән М. Бигиевкә танышу өчен үзендә булган проектларны бирә. Шулай ук, М. Бигиев кайбер документларны төзүчеләрдән алган, дигән хәбәрләр дә бар. Мәсәлән, аның үтенече буенча Хәсәнгата Габәши үзенең проекты текстын почта белән Муса Бигиевкә юллый [Заһидуллин, 2015, б. 128–129].

[2] 1) дәмулла Габдулла Габделкәрим улы Апанаев, Казан имамы; 2) дәмулла Галимҗан Мөхәммәтҗан углы Баруди, Казан имамы; 4) Шиһабетдин Хөснетдин Минуш, Самара ахуны; 5) дәмулла Хәлил Габдегалләм углы Сөләйман, Түбән Новгород шәһәре имамы; 6) Габдулла Габдегалләм углы Нигъмәтулла, Бубый мәдрәсәсенең баш мөдәррисе; 7) дәмулла Габделхак Гыймадетдин, Семипалатта имам-мөдәррис; 8) дәмулла Мөхәммәтсадыйк Госман, Сәгыйд бистәсендә имам-мөдәррис; 9) Габделваһап Габделбари углы Яушев, Петропавел шәһәрендә имам; 10) Мөхәммәтҗан Зәйнетдин углы Янгалыч, Саратов шәһәрендә ахун; 11) Габделгалим Габделгалләм углы Дәүләтшаһ, Оренбургта имам; 12) Мөхәммәтвәли Габделгани углы Хөсәен, Оренбургта мөдәррис; 13) дәмулла Мотыйгулла әфәнде Төхфәтулла, Җаек шәһәрендә ахун-мөдәррис; 14) Мөхәммәткасыйм Мөхәммәтгата хәзрәт углы Мансур, Солтанай авылында ахун-мөдәррис; 15) Мәсгуд әфәнде Билал, Югары Урал шәһәрендә ахун; 16) Сафиулла Максуд, Казан өязе Күлбаш авылында ахун; 17) Хыялетдин Хөсәен углы Хөсникәй, Пермь шәһәрендә мөдәррис; 18) Мөхәммәт углы Дәүликам, Касыйм шәһәрендә ахун; 20) Мөхәммәтйосыф Сәгыйд, Төмән өязе Манчыл авылында ахун; 21) Җәмалетдин Хәрәмшаһ, Бәләбәй шәһәрендә имам-хатип, ахун; 22) Мөхәммәтсабир Мөхәммәтҗан углы Хәсән, Уфа шәһәрендә имам-мөдәррис; 23) Хәйрулла хәзрәт Госман, Уфада мәшһүр мөдәррис, ахун; 24) Хәйрулла бине Габдерахман Госман, Сәгыйд бистәсендә мәшһүр имам-мөдәррис; 25) дәмулла Шәрәфетдин Хәбибулла хәзрәт углы Пати; 26) Хәйретдин Агаев, Мәскәү шәһәрендә ахун; 27) Хәмзә Хәмид, Томск шәһәрендә ахун; 28) хаҗи Гали Гайсә углы, Хан Урдасында ахун; 29) Сабирҗан Гомәр углы Мозаффар, Югары Урал шәһәрендә имам-мөдәррис; 30) Габдрахман Зәбир, Казан өязе Пәрши авылында имам; 31) Салахетдин Бәшир, Троицк өязе Миасс заводында имам-мөдәррис; 32) Габдулла Ибраһим углы Хәрәмшаһ, Стәрлетамак өязе Бозау Яз авылында

имам; 33) Гайнулла Качим, Нократ авылында ахун; 34) Хөсәен Сакал, Пашат авылы ахуны; 35) Мохтар Салах, Әстерхан губернасында ахун; 36) Гатаулла Баязид, Петроградта ахун; 37) Әхмәтшакир Сөендек, Әгерҗедә ахун; 38) Гайнелислам Әхмәтхаҗи углы Мөхәммәтҗан, Пешмә авылында имам-мөдәррис; 39) Мөхәммәтшакир Мөхәммәтхарис углы Тукаев [Җарулла Муса, 1917, б. 13–14].

[3] Русиядә дүрт дини идарә эшли: Тифлистагы Кавказ арты сөнни һәм шигый мәзһәбләрендәге руханилар идарәләре, Уфадагы Мәхкамия шәргыя Ырынбургия, Симферопольдәге Таврия мөселман дини идарәсе.

**Әдәбият**


*Байбулатова Л.Ф.* Проект реформы Оренбургского магометанского духовного собрания в начале XX века // Вестник Казанского государственного университета культуры и искусств. 2015. № 4-1. С. 35–40.

*Дәүләт Н.* Русия төркиләренең милли көрәш тарихы (1905–1917) / төрекчәдән Р. Батулла тәрҗ. Казан: Милли китап, 1998. 399 б.

*Җарулла Муса.* Ислахат әсаслары. Пг.: М.-А.Максутов типографиясе, 1917. 288 б.

*Загидуллин И.К.* Юсуф Акчура о реформировании управления духовными делами мусульман // Симбирский научный вестник. 2016. № 1 (23). С. 123–127.

*Заһидуллин И.К.* Хәсәнгата Габәши хәтирәсе // Фәнни Татарстан. 2015. № 2. Б. 122–139.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. Казан: Татар. кит нәшр., 1984. 7 т.: Тарихи хезмәтләр. Б. 212–435.

*Исхаков С.М.* Первая русская революция и мусульмане Российской империи. М.: Общественно-политическая мысль, 2007. 400 с.

*Сенюткина О.Н.* Первый съезд мусульман России (к 100-летию проведения). Нижний Новгород: Махинур, 2005. 76 с.

Татария в дни первой русской революции / под ред. Х.Г. Гимади. Казань: Таткнигоиздат, 1955. 92 с.

*Фархшатов М. Н.* Петиции мусульман Волго-Уральского региона 1905 г.: о модернизации государственного устройства России // Исповеди в зеркале: межконфессиональные отношения в центре Евразии (на примере Волго-Уральского региона – XVIII–XXI вв.). Н. Новгород, 2012. С. 76–89.

*Хабутдинов А.Ю.* Оренбургское магометанское духовное собрание: планы реформ в начале XX в. // Оренбургское магометанское духовное собрание и духовное развитие татарского народа в последней четверти XVIII – начале XX вв.: материалы одноименного семинара, посвящённого 220-летию учреждения религиозного управления мусульман внутренней России и Сибири (Казань, 18 декабря 2009 г.). Казань, 2010. С. 163–175.

*Хабутдинов А.Ю.* «Голяма җәмгыяте» апреля 1905 г. и проекты реформ Риза Фахретдина // Фахретдиновские чтения. Материалы второй всероссийской научно-практической конференции «Инновационные ресурсы мусульманского образования и культуры: Вторые Фахретдиновские чтения». М.-Н. Новгород, 2011. С. 30–35.

*Хабутдинов А.Ю.* Институты российского мусульманского общества в Волго-Уральском регионе. М.: Изд. дом Марджани, 2013. 344 с.

*Хасанов Х.Х.* Казань в годы первого штурма царизма. Казань: Татар. кн. изд-во, 1985. 191 с.



***Заһидуллин Илдус Котдус улы,***
*тарих фәннәре докторы, ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге*
*Тарих институтының Яңа тарих бүлеге мөдире*

# МӨСЕЛМАН РУХАНИЛАРЫНЫҢ 1905 ЕЛГЫ УФА КОРЫЛТАЕНДА КАРАЛГАН КАЙБЕР ПРОЕКТЛАР[1]

## Корылтайның соң мәҗлесләре

Апрель 12, сишәнбе көн иртә өченче мәҗлес башланды. Мөзакәрә [фикер алышу] остаз Риза әфәнденең ляихә мөсәүвидәсе [караламасы, черновигы] әүзәрендә иде. Проект язмак асан дәгел [җиңел түгел] исә дә, язылмыш проект маддәләренә игътираз [каршы сөйләү, кире кагу] итмәк, маддәләрне интикад [тәнкыйть] итмәк ул кадәр агыр дәгелдер. Буңа күрә, кыйль вә кал [имеш-мимеш, юк-бар сүз] игътираз вә җидаль [кычкырышу, талашу] күбәйде. Шул әснада [арада, чакта] «ляихәи әүвәл мөрәттәб [рәткә салынган, төзелгән] укып, тәмам итмәкме мөнасиб улыр? Яхуд һәрбер маддәне тәмам мөзакәрә итеп, тәдкыйк [җентекләп тикшерү] кылып кичмәкме мәгъкуль улыр?» мәсьәләсе зоһур итте [килеп чыкты]. Әксәрият [күпчелек] карары илә икенче шәкъ [ярык, тишек] ихтыяр кылынып, һәрбер маддә галәхидә [аерым рәвештә, аеруча] мөзакәрә кылыначак, һәм дә кабул кылыначак маддәләр мәҗлес тарафыннан карар вирелмеш, гүя мәҗлес тарафыннан язылмыш хисап кылыначак улды. Наразый [риза булмаучы] адәмнәрнең үз фикерләрендә калмак ихтыярлары да бәян кылынды.

Дүртенче мәҗлес апрель 12 сендә өйләдән соң иде. Әүвәлге кеби маддәләрне мөзакәрә итмәк илә мәшгуль улды. Бишенче мәҗлес апрель 13 ендә, чәһаршәнбе көн иртә. Шул мәҗлестә ляихә мөзакәрәсе тәмам улды.

Апрель 13 ендә, өйләдән соң алтынчы мәҗлес башланды. Мөзакәрә кылынмыш маддәләр хосусында мәҗлес әгъзалары тарафыннан вирелмеш хосусый рәиләр [фикерләр] (мнениеләр) укылды. Буңа магада [башка, бүтән] берничә бәяннамәләр кыйраәт кылынды [укылды].

Йосыф әфәнде Акчура каләме илә язылып, мөхтәрәм алты әфәнде тарафыннан имзаланмыш, 46 маддәдән гыйбарәт ляихә гаризасы югарыда (42–49 сәхифәләрдә) нәкыль [күчерү] кылынмыш иде. Иштә ул ляихә мәҗлес исеменә вирелеп, алтынчы мәҗлестә мөзакәрә юлында укылды. Бунның биркәсендә [аркасында] корылтай алында [кулында] гаять мөһим ике ляихә [проект] хасил улды: бере, әүвәлге ляихә – Риза әфәнде хәзрәтләренең ляихәсе; дигәре, икенче ляихә – Йосыф әфәнде каләме илә язылып «Тиҗар [сәүдәгәр] вә әгъян [югары дәрәҗәле түрәләр, башлыклар] ляихәсе» исеме илә аталмыш ляихә иде.

«Бунлара башка янә берничә проект укылды, күрелде исә дә, мөфти әфәнде тарафыннан язылмыш проект мәҗлескә вирелмәдегеннән, башкалары исә ялгыз дин мәсьәләләренә

---

[1] *Җарулла Муса.* Ислахат әсаслары. Пг.: М.-А.Максутов типографиясе, 1917. Б. 77–90.

гаид улмадыгыннан, анларны бу раддә [дәрәҗәдә] язмак зарурәте [үтә кирәклек] юктыр». Шул сүз «Корылтай» исемле әсәрендә остаз мөхтәрәм Риза әфәнде хәзрәтләренең сүзедер. Укылмыш проектларның бәгъзеләрен түбәндә, иншалла, бәлки нәкыль идәрем.

Апрель 14 ендә, пәнҗешәмбе көн иртә җиденче мәҗлес башланды. Әүвәлге мәҗлесләрдә натәмам [бетмәгән] калмыш байтак мәсьәләләр тәкрар [кабат] кылынды. Риза әфәнде ляихәсе илә Йосыф әфәнде ляихәсеннән кабул кылынмыш маддәләрне интихаб кылып [аралап алып] язмак өчен әгъзалар арасыннан дүрт адәм тәгъйин кылынды [билгеләнде]. Кабул кылынмыш маддәләрне тәртип кылып язмак вазыйфасы ике көн эчендә тәмам улып, мәҗлес әгъзалары тарафыннан да имзаланып, мөфти хәзрәтләренә тәслим кылынды [тапшырылды].

Апрель 15 ендә, җомга көн иртә сигезенче мәҗлес башланды. Шул мәҗлес мөзакәрә мәҗлесе улмаеп, бәлки корылтай мәҗлесләренең мөфти әфәнде тарафыннан ябылмасыннан гыйбарәт иде. Мөфти хәзрәтләре хәзрәтләргә шул сүзләрне сөйләде:

«Һәр нәкадәр юлларның фәна [юкка чыгу, бетү] вакыты исә дә, килеп, әһәмиятле мәсьәләләрне мөзакәрәләреңездән шатландык. Бөтен Русия мөселманнарына гаид мөһим мәсьәләләрдә аз адәм тарафыннан эшләнер исә, бөек ялгышлыклар булачагы бик мөмкиндер. Буңа күрә күп затларның иҗтимагы лазем улды. Ләкин мөфти улачак затны мувәкъкать [вакытлыча] сайламак мөселманнар өчен файдалы улмас, зан идәрем [дип уйлыйм]. Бунда бәнем өчен бер файда, бер зарар юктыр. Мувәкъкать сайланачак мөфтиләрнең хөкүмәт күзендә игътибары калмаса кирәк. Мәҗлесләреңездә мөзакәрә кылынмыш мәсьәләләрнең һәрберен айларча мөзакәрә итмәк тиеш исә дә, мөсагадә [булышу, ярдәм итү] кылынмыш мөддәт аз иде, мөзакәрәләрне мөмкин кадәр кыска итмәк лазем улды. Сезнең мөзакәрәләреңезгә мәәхәз [чыганак] улмыш бөтен мәгълүматны хәзер итеп куючы Риза казыйдыр. Риза әфәнденең шул тугрыда гаять бөек иҗтиһады [тырышлыгы] улды. Буңа күрә, бән үз тарафымнан аңа рәхмәт әйтәм. Инде мәҗлес шул сәгатьтән башлап ябылды. Аллһу тәгалә хәерле итсен».

Мөфти Мөхәммәдъяр әфәнде хәзрәтләренең шул сүзләре илә корылтай мәҗлесләре тәмам улды.

Корылтайның биш көн дәвам итмеш мәҗлесләре Русия мөселманнарының тарихында гаять әһәмиятле хадисәләрдән [вакыйгалардан] игътибар кылынмак тиештер. Собрание тарихында исә фәүкылгадә [гадәттән тыш] хадисә иде. Корылтай мәҗлесләренә тәкъдим кылынмыш гаризаларның, ляихәләрнең бәгъзеләрен бу раддә нәкыль итеп, буннан соң янә корылтай мәҗлесләренең карарларыннан бәхәс идәрез.

### Уфа шәкертләренең гаризасы

Күптән көтелеп тә бүген генә сезнең риясәтеңез тәхетендә

[җитәкчелегез астында] тупланмыш «Җәмгыяте исламия»дә хосусы илә мәктәп, мәдрәсәләрнең, шәкертләрнең, руханиларның хәлләрен ислах чаралары мөзакәрә кылыначагына күрә, түбәндәге маддәләрне җәмгыятьнең мөхакәмәсенә [хөкем чыгаруга] без, таләбәләр тәкъдим иттек. Рәҗамыз [үтенечебез] сезнең һәм җәмгыятьнең илтифатына бәлки наил улыр [ирешер].

1) Мәгариф назыйрының [мөдиренең, министрының] һичбер мөдахәләсе [катышы] улмаеп, мәктәп-мәдрәсәләремез ялгыз собрание идарәсенә табигъ [буйсынучы] улса иде.

2) Мәктәп-мәдрәсәләргә мәҗлесләргә нәзарәт [күзәтү, идарә итү] өчен собраниедә аеруча шөгъбәләр булынып, назыйрларның, мөмәйизләрнең [яхшыны-яманны аеручы, акыллы] рәисләре ул шөгъбәләрдә әгъза улсалар иде.

3) Собраниедә әүкаф [вәкыфлар] өчен йәнә махсус бер шөгъбә булынып, бөтен әүкафларга һәм дә бөтен җәмгыяте хәйрияләргә нәзарәт итсә иде.

4) Собрание мәктәп-мәдрәсәләремезне дүрт дәрәҗәгә тәкъсим итеп; ибтидаия [башлангыч], рөшдия [башлангычтан югары (урта) мәктәп], игъдадия [мәдрәсәдә югары белем алуга хәзерләү класслары], галия исемнәре илә тәсмия итәр. Шул дәрәҗәләрнең һәрберендә өч сыйныф улып, мәҗмугы 12 дән; яхуд 4 сыйныф улып, мәҗмугы 16 дан гыйбарәт улыр.

5) Ибтидаи мәктәпләргә кабул кылынмак өчен яше сигездән аз улмамак, һәм дә һәр ай бер микъдар парә вирмәк мәҗбүри улса иде.

6) Рөшди мәктәпләргә кабул кылынмак өчен я ибтидаи мәктәп шәһадәтнамәсе, я дөхуль [керү] имтиханы шарт кылынып, һәм дә һәр ай бер микъдар парә вирмәк мәҗбүри улса иде.

7) Игъдади мәктәпләргә кабул кылынмак өчен йә рөшди шәһадәтнамәсе йә дөхуль имтиханы шарт кылынып, һәр ай бер микъдар парә вирмәк мәҗбүри улса иде.

8) Галия сыйныфларына кабул кылынмак өчен йә игъдади шәһадәтнамәсе яхуд дөхуль имтиханы шарт кылынып, мөгаен бер микъдар вирмәк мәҗбүри улса иде.

Шәкертләрдән мәктәп өчен алыначак микъдар, мәсәлән шөйлә [шул илә, шулай] улыр: ибтидаи мәктәп сыйныфларына сәнәлек биш рубль; рөшди сыйныфларына сәнәлек ун рубль; игъдадиларга 15 рубль; галия сыйныфларына 25 рубль улмак кеби.

9) Рөшдидән шәһадәтнамәсе бар зат ибтидаи мәктәптә мөгаллим ула булыр. Әгәр дә мөгаллимлек вазыйфасында хезмәте яхшы улмаса, мөәзин тәгъйин кылынса иде.

10) Игъдадидан шәһадәтнамәсе бар әфәнделәр рөшдидә мөгаллим, мәхәлләдә имам улыр.

11) Галия сыйныфларыннан шәһадәтнамәләре бар әфәнделәр игъдади мәктәпләрдә мөгаллимлек кылып мәләкә [өйрәнү, остару] тәхсил итсәләр, галия сыйныфларына мөгаллим улыр. Әгәр дә галия сыйныфларында мөгаллимлек кылып мәләкә тәхсил итеп яхшы хезмәт күстерсәләр

назыйр, мөмәйиз, мәгариф шөгъбәсендә әгъза, собраниедә казый улмак шәрәфләренә дә мөстәхикъ [хаклы, лаеклы] улыр.

12) Кабул парәсе һәр мәктәптә һәр сыйныфта шарт кылынса, мәктәп нәфәкасы [кирәк-ярагы] өчен бер микъдар парә, әлбәттә, тупланыр.

13) Никах мөһерләреннән һәр рубль башына өч тиен хәйрат сандыкларына вирелсә иде.

14) Талакта, хатын дәгъва итәр исә, рубль алмак, ир дәгъва итәр исә, өч рубль алмак рәсем [гадәт] улса иде.

15) Метрика дәфтәрләренә балаларның исемнәрен кайд иттермәк [беркетү, теркәү] өчен ля әкалле [иң кимендә] 20 тиен алынмак рәсем улса иде.

16) Фарыз садакалары тупламак өчен «гамил садака»лар нәсыб кылынып [билгеләнеп], һәр сәнә зәкят, гошер, фытыр, корбан кеби садакалар тупланып, җәмгыять хәзинәсенә тәслим кылынса иде.

17) Кирәк хөкүмәттән, кирәк башка бер җирдән мәгаш алучы әфәнделәр мәгашләреннән һәр ай ля әкалле бер процент җәмгыять хәзинәсенә вирсәләр иде.

18) Собрание идарә итмәк, мәктәп, мәдәрәсә, мәсҗед бина итмәк хосусларында дәүләт хәзинәсе тарафыннан азмы-күпме иганә вирелсә иде.

Шул 12–18 рәкымнарда күстәрелмеш мәбләгалардан [акча күләме] имамлык, мөгаллимлек, мәктәп-мәсҗед хадимнәренең мәгашләре бераз гына исә дә бәлки тәэмин кылыныр.

19) Һәр карьяда ибтидаи мәктәп; һәрбер бөек карьяда ибтидаи мәктәп өстенә рөшди мәктәп; мөселманнары күп өяз шәһәрләрендә ибтидаи, рөшди мәктәп өстенә игъдади мәктәп; вилаят шәһәрләрендә, мөселманнары күп улыр исә, бунларга башка янә бер гали мәктәп ачылса иде. Кызлар өчен дә һәр карьяда ибтидаиләр, бөек карьяларда рөшдиләр, шәһәрләрдә игъдадилар ачылса иде.

20) Мәдрәсәләрдә гарәби, фарси, төрек, татар, рус лисаннары тәгълим кылынып, голүме диниядән: хәдис, тәфсир, тарихе мөкаддәс, фәлсәфәи диния, гакаид, фикъһе, әдәбияте гарәбия, бәлягате гарәбия; фөнүннән: хисап, һәндәсә, җәгърафия, тарихе гомуми, тарихе рус, тарихе шәрекъ, хокукы дөвәл [дәүләтләр], рус кануннары тәгълим кылынса иде.

21) Волостьларда, һич улмас исә, өязләрдә, мөгаллимнәрне мөселман улмак шарты илә, хөкүмәт тарафыннан тиҗарәт, сәнагать, зирагать мәктәпләре бина иттерелсә иде.

22) Волостьларда, өязләрдә, вилаят шәһәрләрендә мөселманнар өчен дә кыйраәтханә ачылса иде.

23) Нә җирдә гали мәктәп вар исә, ул җирдә бөек бер көтебханә тәэсис кылынса иде.

24) Мәктәп-мәдрәсәләрнең низамнарына, програмнарына муафыйк дәрес китаплары тәэлиф иттермәк җәһәтләренә рәваҗ [таралу] вирмәк өчен, гүзәл дәрес китабы тәэлиф итәчәк әфәнделәргә хосусый бер имтияз [мактау кәгазе] вирмәк, каләм һәдиясе [бүләге] дә вирелсә иде.

25) Җәмгыять хәзинәсе хисабына, ятим балалар өчен тәрбия йортлары бина кылынып, аталары фәкыйрь балаларны ибтидаи, рөшди, игъдади, гали мәктәпләрдә тәгълим итмәк әҗерәсе [түләве] җәмгыять хәзинәсеннән вирелсә иде.

26) Җәмгыять хәзинәсе мөселманнарга махсус җәридә [газета], мәҗәллә [журнал] нәшер итсә иде.

27) Тәгълим һәм голүм эшләрендә хезмәтләре, мәһарәтләре исбат кылынган голәмәдән, җәмәгать эшләрендә иҗтиһадлары, әманәтләре, һиммәтләре күренгән адәмнәрдән мөрәккәб [бергә җыелган, кушма] бер һәйәт хаҗәт тәкъдирендә, могаен вакытларда дәгъвәт кылынып, мөселманнарның милли, иҗтимагый хаҗәтләре мөзакәрә кылынып торса иде. Мәктәп-мәдрәсәләрдә мәгариф юлларына җәмгыять хәзинәсеннән сарыф кылынмыш мәбләгъләры [акча күләме] ихтисаб иттермәк өчен хосусы илә һәр сәнә бер җәмгыять тәшкил кылынса иде.

28) Шул сәнә дәгъвәт кылынмыш «Галимнәр мәҗлесе» буннан соң һәр сәнә дәгъвәт кылынып, дини-иҗтимагый хаҗәтләремез һәрвакыр мөзакәрә кылынып торса иде.

Шул 28 маддәдән гыйбарәт гариза 90 шәкерт имзасы илә мөфти хәзрәтләренә, «Голәмә мәҗлесе»нә тәкъдим кылынмыш. Хәзрәтләрнең илтифатларына наил улып-улмамак мәсьәләсе бәңа мәгълүм улмады. Буннан соң да шәкертләрнең хәрәкәтләрен, иншалла, нәүбәтлә бәян идәрем.

**Мәҗлестә хазир дәгъвәтле хәзрәтләр тарафыннан имзаланып, хөкүмәттән соравы тиеш табылган эшләр:**

1) Мөселманнарга имин һәр җирдә мөселман руханилары хозурында улып ислам лисанында улса иде.

2) Ислам карьяларында ислам балалары өчен русский класс тәклиф кылынмаса иде.

3) Ислам хаҗиләренең паспортлары христиан паломникларының паспортлары бәһасендә улып, һәр җирдә һәрвакыт биля мөманәга [каршылыксыз] вирелсә иде.

4) Ислам гаскәри хокукта рус гаскәрилә бер дәрәҗәдә улса иде.

5) Ислам гаскәриенә тиешле кадәр имамнар нәсыб кылынып [билгеләнеп], ислам руханилары хокукта рус руханилары кеби улса иде.

6) Шәригате исламиядә хәрәм тәгамнан, шәраптан ислам гаскәри мәнгы кылынып, дини вазыйфаларын әда сәгатьләрендә һәрвакыт мөсагадә вирелсә иде.

7) Ислам галимнәренә, бәлки гомумиятьлә мөселманнарга русча уку тәклиф кылынмаса иде.

8) Имамнарның, ахундларның һәрберенә хәзинә мөһере вирелеп, эш кәгазьләре почтада мәҗанән [түләүсез, бушка] йөртелсә иде.

9) Руханиларның һәрбере гаскәрлек хезмәтләреннән азат кылынса иде.

10) Заграницада тәхсил итмәк руханилык, мөгаллимлек, мөдәррислек хезмәтләренә манигъ кылынмаса иде.

11) Нә рәддә табигъ кылынмыш исә дә, яхуд дәстхат

[кульязма] улса да, дини китаплары укытмактан манигъ булынмаса иде.

12) Коръән кәримгә, шаригъ хәким галәйһи әс-салат вәссәлам хәзрәтләренә, динемезгә тагын юлында язылмыш бәндәләргә рисаләләргә мокабил, хакыйкатьне бәян итеп җавап язмак мәҗбүриятенә һәрвакыт мөсагадә вирелсә иде.

13) Компанияләр, ширкәтләр тәшкил итмәк, Русиядә һәр җирдә милек ала белмәк хосусларында мөселманнарның хокуклары руслар илә бер дәрәҗәдә улса иде.

14) Диннәрен, лисаннарын, язуларын белүләренә шәһадәтнамәләре юк ислам балалары рус мәктәпләренә кабул кылынмаса иде.

15) Кыргыз, казак, төркмән балаларын мәктәп-мәдрәсәләремездә укытмактан; кыргыз, казак, төркмән арасында мөгаллим, имам, мөдәррис улмактан манигъ итмәк алга кылынса иде.

16) Башка диннәрнең беренә мөртәд улачак мөселманнарны алты һәфтә вәгазь итеп, шөбһәләрен хәл итмәк хакы голәмәләргә вирелсә иде. Бөлүгъдан элек иртидад хакы һичбер сурәт илә вирелмәсә иде.

17) Падишаһлык бәйрәмнәреннән, үзләренең дини бәйрәмнәреннән башка вакытларда эш туктатмак, сәүдә вә дөкяннәрен япмак мөселманнарга тәклиф кылынмаса иде.

18) Әхлакларын төзәтеп, дини әдәпләрен бәян итмәк өчен үз лисаннарында җәридә, мәҗәллә нәшер итмәк хакы мөселманнарга да вирелсә иде.

**Габдулла әфәнде Диберди тарафыннан күндерелмеш гаризада 25 маддәдән бәгъзеләре:**

1) Мәктәп, мәдрәсәләр ялгыз собрание идарәсендә улып, дахилия назарәте дә мәгариф назарәте дә мөдахәлә итмәсә иде. Ибтидаи мәктәпләремезгә, дини мәдрәсәләремезгә хөкүмәтнең мөдахәләсе динемезгә хөкүмәтнең мөдахәләсе кебидер. Дәүләт мәслихәтләре ноктасыннан да мөдахәлә файдасыздыр. Инспекторларның, миссионерларның мөдахәләләре укудан мөселманнарның күңелләрен биздерде, халыкта әхлак фәсадына сәбәп улды.

2) Собрание голүме диния тәгълименә махсус мәктәп-мәдрәсәләргә һәр шәйдән зиядә әһәмият виреп, һәрбер карьяда мәхәллә хезмәте илә мәшгуль имамнан башка, мәхәллә хезмәтләренең һичбере илә мәшгуль түгел бер мөдәррис я бер мөгаллим тәгъйин итсә иде.

3) Әүкаф, зәкят, хәйрат кеби мәнбәгълардан бер сәрмая тупланып; мәктәп, мәдрәсә, мәсҗедләрне тәрбия өчен собрание хозурында бер комиссия тәшкил кылынса иде.

4) Руханиларны, мөгаллимнәрне, мөдәррисләрне һәм нәсыб итмәк һәм гозел итмәк ялгыз собрание ихтыярына махсус кылынып, шул хосусларда вилаять правленияләренең мөдахәләләре катгый сурәттә алга кылынса иде.

5) Яңабаштан мәктәп, мәдрәсә, мәсҗед биналарына рөхсәт вирмәк ялгыз собрание ихтыярына хәсыр кылыныр, консисторияләрнең христиан идарәи

руханиялəрнең һичбер сурəт илə мөдахəлəлəре булынмаса иде.

6) Бер мəхəллə үзенə мөгаллим я мөдəррис талəп идəрсə, сəнəви мəгашлəрен тəэмин итə белер кадəр мəблəгый җəмəгатьтəн имзалар илə илтизам иттереп, хөкүмəт мəэмүрлəре васитасилə һəр сəнə əһалидəн əү мəблəгъ тупланып собрание васитасилə сахиблəренə тəүзигъ [тарату, өлəшү] кылынса иде. Əгəр дə мəхəллəдəн туплана булачак мəблəгъ мəктəпнең мөгаллимнəрнең нəфəкаларына кифаять итмəс исə, собрание тасрифында булыначак маядан тəкмил кылынса иде.

7) Цензура тəмам лəгу кылынып [бетерелеп], үз лисанымызда җəридə, мəҗəллə нəшеренə там хөррият вирелсə иде. Чит мəмлəкəтлəрдəн ислам китапларын җəлеп итмəк цензор назарыннан азат улса иде.

8) Руханилар гаскəрлектəн азат улып, имамəт өчен яшь шарт кылынмаса иде.

9) Никах өчен алына торган 25 тиен өстенə янə 75 алынып, мөселманнарның мəгариф сəрмаясенə тəхсыйс кылынса иде.

10) Ислам балаларына махсус приютлар мəгариф назарыннан алынып, собрание идарəсенə тəслим кылынса иде; мөгаллим, мөгаллимəлəрне, мөрəббиялəрне мөселман улмак шарт кылынса иде.

11) Төркестанда, Русия мəмлəкəтлəренең һəр җирендə җир вə милек алмак хокукы мөселманнарга руслар илə бер дəрəҗəдə вирелсə иде.

12) Керəшен исемендəге мөселманнарның хəллəре хакында мəгълүмат тупланып, хокукы диниялəренə мөсагадə алмак хосусларында мөнасиб юллардан хəрəкəт кылынса иде. Ягъни рəсмəн ислам танылып мəхəллəлəренə мəктəп, мəсҗедлəренə рөхсəт вирелсə иде.

13) Кыргыз, казакъ, төркмəн араларына варып балаларын укытмак мөгаллимнəремезгə манигъ кылынмаса иде.

14) Русиядə, шаять, халык представительлəренең парламенты була калса, һəр җирдə үзлəренең гадəдлəренə күрə мөселманнардан да вəкиллəр сайланса иде.

### Тын карьялардан бөек тавыш

Мөхтəрəм казый Ризаэддин əфəнде хəзрəтлəре!

Уфада апрель 10 нда бөек галимнəр иҗтимаг итеп миллəт эшлəре хакында мөзакəрə, мөшəвəрə итəчəклəре мəсмугатымыздан улды [хəбəре ишетелде]. Ул илə бөек мəҗлеслəргə хазир улмак шəрəфлəренə безем кеби гаҗиз имамнарның истихкаклары, салахиятьлəре юк исə дə, миллəт намына исламият файдасына фикеремезне язып, сезгə күндермəк безгə һаман ваҗиб улса кирəк.

Русиядə бөтен миллəтлəрнең хөррияте диниялəре хакында 1904 сəнə декабрь 12 ндə император хəзрəтлəренең фəрман шаһанəлəрен күреп укып шатландык, этраф галимнəре илə мөзакəрəлəргə, мөшəвəрəлəргə чумдык. Ул бөек фəрман шаһанəдəн истифадəмезне арзу итеп, 1905 сəнə январь 24 ндə Гундыр ярмаркасында җитмештəн зиядə галимнəр тупланып, мөшавəрə соңында император хəзрəтлəре-

нә дүрт мәтлабтан гыйбарәт гаризамызны күндермәк карарын кабул иттек. Гаризамызны хәзерләдек. Голәмә, әгъниядән 200 гә кариб имза илә гаризамызны тиеш мәхәленә [урынына] күндердек. 1905 сәнә февраль 18 ндә император хәзрәтләренең янә фәрман шаһанәләрен күреп, ялгыз руханилар улмак шарты илә бәнем ханәмдә янә тупландык. Русия мөселманнарының ихтыяҗларын сөйләдек. Иң мөһимнәрен 6 маддә әүзәренә ихтисар итеп, Петербургта яңа ачылмыш назыйрлар шурасының рәисе Витте хәзрәтләре намына күндердек. Без, руханилар, боларда һәрнә кадәр мәхәлли хөкүмәт кешеләренең бөек тәһдидләренә [куркыту, янауларына] гөрефтар [тоткын] улып торсак та, мөселманнарның шул көнге форсатларын хәтердән чыгармаеп, мөселманнарның колакларына үзләренең хаҗәтләрен тәлкыйн итүдән, император хәзрәтләренең гадаләтләрен, мәрхәмәтләрен рәҗа вә нияз иттерүдән һичбер вакыт кире тормадык. Соң гаризамызда күстерелмеш матлаблар шулдыр:

1) Мөфти голәмәдән улып, интихаб хакы мөселманнарның үзләренә тәслим кылынмак. Собрание казыйларны да шул илә. Рухани эшләр бөтен тәфригате илә, мәсәлән, руханиларны насыб итмәк, гозел итмәк, дәрәҗәләрен рәфыг итмәк, мәктәп, мәдрәсәләрне, мәсҗедләрне идарә итмәк, биналарына изен вирмәк, һәммәсе собрание алында улыр. Рухани эшләргә башка мәхкамәләрнең һичбер мөдахәләсе улмас. Һәм дә руханиларга илзам кылынмыш русча фәсех кылынмак, руханилар хезмәт гаскәриядән азат улмак.

2) Никах, талак, мирас кеби гаилә мәсьәләләре бөтен фөругаты илә шәригате исламия ысуллары әүзәрендә иҗра кылынып, мал дәгъвалары да ислам галимнәренең фәтваләренә, казаларына күрә катгы ителсә иде.

3) Ислам гаскәриләре шәригате исламиядә хәрәм тәгамнардан, шәраплардан сакланса иде, мөселманнарга диннәрен тәлкыйн итеп дини вазыйфаларын әда иттерү өчен һәр полкта имамнар нәсыб кылынса иде, рамазан шәрифтә рузаларына мөсагадә виреп, ашлары-сулары руза сәгатьләренә күрә улып, хезмәтләре дә руза көннәренә күрә асанлаштырылса иде.

4) Диннәргә һәр җәһәт илә хөррият вирелеп, матбугатта да хөрриять вирелсә иде.

5) Русларга вирелмеш бөтен мәдәни хокук мөселманнарга да вирелсә нииде. Мәсәлән, мәхкамәләрдә хаким улмак, русларның мәктәпләрендә мөгаллим профессор улмак, уфак бөек идарәләрнең һәрберендә чиновник улмак кеби.

6) Руханиларга дахили, хариҗи паспорт вирә белмәк собрание ихтыярында улса иде.

Гадаләтле, мәрхәмәтле император хәзрәтләренең декабрь 12 сендәге фәрман шаһанәләре Русиядә бөтен тәбәгаларга хөррият, мөсавәт, гадаләт, сәгадәтләрен ихсан итте. Шул бөек өч кәлимә ялгыз кәгазь өстендә язылып кына калмаеп, бөтен халыкның көндәлек хәятләренә, хаҗәтләренә дә татбикъ кылынмакларын һәммә

халык арзу итәләр. Безем мөселманнарның иң мөһим хаҗәтләре дә, бөтен хокук та руслар илә мөсави улып, Русиядә яшәмәк, эш күрмәктер. Шул көн хокукларның әксәреннән мәхрүмиятемез өчен дә, ачылмыш милләт мәҗлесеннән хокукымызны милләт өчен таләп итмәгә хакымыз, әлбәттә, вардыр.

Мәгълүм, безем ислам галимнәре нәсари руханиларыннан сад мәрхәлә әдвән вә әсфилдер. Җөмлә милләтләрнең һәрбер хокук гомумиядә бәрабәрлеге гадаләтнең иң беренче шартыдыр, сәмәрәседер.

Таләп кылыначак безем хаҗәтләремез дә, хокукларымыз да бигүк күп, хокукларның дәрәҗәләре дә мөтәфавиттер [төрледер]. Мәсәлән: ибтидаи мәктәп мәсьәләләрендә һәр җәһәт илә там хөррият хакы ибтидаи мөкаддәс бер хакымыз исә, әксәрияте исламнан гыйбарәт вилаятьләрдә вәлиләре, губернаторлары мөселманнардан тәгъйин итмәк милли шәрәфемезнең хакыдыр. Бу илә улса иде, хөкүмәттә дә бу бөек файдалар мәнфәгатьләр хасыйл улыр иде. Халык тәгълим, тәрбия җәһәте илә тиз тәрәккъый итәр иде, хөкүмәтнең бөтен фәрманнары да асанлыкла нөфүз итәр иде.

Русча белмәк, ихтыярый сурәттә рус мәктәпләрендә тәрбия күрмәк безем өчен гаять файдалыдыр, бәлки һәр җәһәт илә заруридыр. Ләкин һәрбер кавемнең, һәрбер милләтнең ана лисанында иң әүвәлге тәрбиясе иң әүвәл арзу кылыначак хаҗәтләрдәндер. Буңа күрә, ислам карьяларына бина кылмыш һәм кылыначак сельский школаларда русча нәкадәр укылса, мөселманча да ул кадәр укытмак һәм халык өчен, һәм хөкүмәт өчен һәр җәһәт илә файдалыдыр. Русча һәркөн 3 сәгать дәрес вирелсә, мөселманча да ул кадәр; русча укучыларга бөтен хаҗәтләре земстводан вирелсә, мөселманча укучыларга да вирмәк лазем. Русча учитель һәр ай 25 рубль алса, мөселман мөгаллиме дә, мөгаллимәсе дә ул кадәр алмак, әлбәттә, тиештер. Сельский школаларда русча уку шул көн өч сәнә исә дә, мөселманчасы илә бәрабәр биш сәнә улса, нә улыр. Русча дәресләрдән инспектор имтихан итәр исә, мөселманча дәресләрдән ислам галимнәренең бере яхуд махсус тәгъйин кылыначак бер мәмйиз имтихан итәр. Юкса, хәзерге кеби һәфтәдә бер-ике дәфга барып, һәфтияк һәҗаләрен [иҗекләрен] дә белдермәмәк шарты илә укытмактан нә бер мәгънә, нә бер файда хасыйл улыр. Балаларның гомерләрен заегъ итмәктән башка бер файда чыкмас.

Халыкның лисаны да хөкүмәт лисаны да бер дәрәҗәдә гүзәл ысулда укытылса, халык өчен дә, хөкүмәт өчен дә бөек файдалары хасыйл улыр. Алмания, Англия, Австрия кеби мәдәни мәмләкәтләрдә шул ысул җаридер [кулланыладыр]. Шуңа күрә ул мәмләкәтләрнең халкы басыйрәтледер, тәрбияледер.

Хәзерге һәм киләчәк балаларның күзләрен ачып, бөтен Русия мөселманнарының гүзәл истикъбальләрен тәэмин итмәк өчен, мәктәп-мәдрәсәләремезнең начар җәһәтләрен тәмам

төзәтмәк һәм дә мөнтазам [тәртипкә салынган] ысул истикамәтендә [дөрес юнәлешендә] тәгълим-тәрбия юлларын бүген хәзерләмәк безгә, әлбәттә, һәр шәйдән зиядә лаземдер. Башка һәрбер милләт уянып, җанланып, иҗтиһад итеп торганда, без һаман әүвәлгечә гафләттә калыр исәк; мәгърифәтле, мәдәниятле милләтләрнең иң дүн [түбән] хадимнәре улып калачагымыз кояш кеби заһирдыр.

Мәктәп-мәдрәсәмезне ысулы тәгълим тәрбиямезне ислах өчен, әлбәттә, безгә сәрмая лазем улачак, парә лазем улачак. Мөкаддәс Коръән кәрим әмере илә бөтен мөселманнарга фарыз кылынмыш гошер, зәкят, фытыр, корбан кеби садакалары милли бер хәзинәдә, бәйтелмалда гамәлләрнең иганәсе илә тупласак, ма хасилның ля әкалле өчтән берен мәктәп-мәдрәсә юлларына сарыф итсәк, бәкыясы мәхәллә руханиларына дәрәҗәләренә, хаҗәтләренә күрә тәүзигъ кылынса гүзәл улмасмы? Хөкүмәт буңа, иншалла, мөсагадә итсә кирәк. Зирә һәм хөкүмәткә, һәм бөтен мөселманнарга файдалыдыр.

Русия мөселманнарының шул көнге хәлләрдән нәҗатлары [котылу] өчен ике шәй лаземдер: бере мәктәп-мәдрәсәләрнең интизамы, дигәре галимнәрнең милли, дини хаҗәтләремезне мөшавәрә мөзакәрә хакында иттифакларыдыр. Руханилар, галимнар иттифак итсәләр, соңра милләтне дә эш берлегенә дәгъвәт итсәләр, һәр мөшкелнең чарасы булыныр.

Гадаләтле император хәзрәтләренең фәрман шаһанәсе илә милләт мәҗлесе дәгъвәт кылыныр исә, хәмиятьле, мәгълүматлы, моктәдир мөселман вәкилләрен интихаб итеп күндереп, Милләт мәҗлесе трибунасында үз таләпләремезне гарыз иттермәк, бөтен хокукларымызны хөкүмәт һәм вәкилләр хозурында химая иттермәк безгә, әлбәттә, лазем улачактыр. Ислам вәкиле кылыначак адәмнәргә хокукы исламия, исламиятне, мөселманнарның хәлләрен, хаҗәтләрен һәр җәһәтлә гүзәл сурәттә белмәк, әлбәттә, тиеш улса кирәк. Ялгыз русча белү кяфи улмаса кирәк, Милләт мәҗлесендә ислам галимнәреннән хәмиятьле, бәсыйрәтле, мәгълүматле затлар исбат вөҗүд итмәк иң арзу кылыначак әмәлләрдәндер.

Шул көннән соң, Уфада һәр сәнә бер мөнасиб мөгъйин вакыт галимнәр, мәгариф әсхабы, бәсыйрәт әрбабы иҗтимаг итеп, мөселманнарның мөһим хаҗәтләре хакында мөзакәрә мөшавәрә итә торсалар, милләт тиз заманда җанланып яңа хәят юлларына аяк басар иде.

Шул көнге иҗтимагый хәлемезгә интикад күзе илә нәзар итәр исәк, өмид вирә белерлек бер нур һәрбер җәһәттә күренмәс. Мәктәп-мәдрәсәләремезнең һичбере тәэмин кылынмаган. Дөрест, бәгъзе бер һиммәтле хәмиятьле бай әфәнделәр тарафыннан бина кылынмыш гүзәл генә мәдрәсәләремез вар исә дә, мөрәббиләре киттекеннән соң ул мәдрәсәләрнең дә хәлләре тәэминсез калачактыр, буның өстенә 15–20 миллион мөселман өчен 5–10 мәдрәсә тәмам юк мөнәсәбәтендәдер. Сәрмаяләре азлыктан улса кирәк, җәмгыяте хәйрияләремезнең халык өчен бәрә-

кәтләре аздыр. Нә диик, хәлемезнең гакыйбәте хәер улса иде.

Ауропа мәктәпләренә иң истигъдадлы таләбәләремезне тәхсил тәрбия өчен күндереп, һәр сәнә ля әкалле [иң кимендә] 30–40 таләбәмезне, тәхсил тәмам итмеш яшь егетләремезне кайтарып тормак, ислам мәркәзләренең һәрберендә һөнәр мәктәпләре, санагать мәдрәсәләре ачып ислам балаларын һөнәр, санагать юлларына сәвекъ [юнәлтү] итмәк, безем өчен һәм лазем һәм мөмкин исә дә, ләкин шул көнге хәлемезгә хиссиятемезгә күрә, ялгыз бер хыялдыр.

Ихтыяҗларымыз хакында без бәлки дәһа зиядә язар идек, ләкин сүз язуда файда юк, әһәмият юк. Бөтен әһәмият эштә. Инде эш кирәк!

1905 сәнә, апрель 6 сында.

Имзалар:

Уфа вилаяте Бөре уезды, Тау карьясында имам Сәһман Исхакый хәзрәт ханәсендә тупланмыш хәзрәтләр.

Әтраф карьялардан имам Сәһман әфәнде ханәсендә тупланып мөзакәрә итмеш хәзрәтләрнең остаз мөхтәрәм Риза әфәнде хәзрәтләре исеменә шул мәктүпләрне «Тын карьялардан гаять бөек тавыш» иде. Шул мәктүпнең, бәнем нәзарымда, бер кач җәһәтлә гаять бөек әһәмияте вардыр.

1. Бере мохтасарлыгы илә бәрабәр җамигъ улмак җәһәте. Корылтай мөзакәрәләрендә кабул кылынмыш карарларның бөтен әсасларын җамигъдыр; байтак мөһим зиядәләре дә вардыр.

2. Хәзрәтләрнең мәктүбе улмак җәһәте. Иң хөрриятле зыялыларымызның фикере дә шул мәктүпнең фикереннән тугры, ачык улмас. Карья хәзрәтләре арасында бу илә сималарны күрмәк безгә һәм шатлык һәм өмид вирер.

3. Соң 10 сәнә эчендәге съездлар карарларының бөтен милләт карары, бөтен милләт таләбе икәнлегенә гаять ачык даләләт итмәк җәһәте. Почтадан озак һәм дә матбугат нурларыннан мәхрүм карьяларда, съезларның һәрбереннән мөкаддәм бер заманда язылмыш бер мәктүп карарларының бөтен әсасларын җәмигъ итмеш исә, карарларның һәрбере бөтен милләтнең калебеннән чыкмыш улыр.

Мәктүпнең бөтен әһәмияте дә бу раддә шул җәһәттәндер.

*Текстны гарәп имласыннан кирилл алфавитына күчереп,*
*сүзлекне һәм аңлатмаларны Казан федераль университетының*
*Н.И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханә хезмәткәре*
***Шәрәфиева Рәисә Гамир кызы** әзерләде*